

- М. Кәримнең яшәгән еллары?
- Нинди гаиләдә туган?
- Кайларда белем алган?
- М. Кәримнең балачагы кайда үтә?
- Бөек Ватан сугышында катнашканмы?
- Язган әсәрләренең кайберләре?

- 1919 – 2005
- Урта хәлле крестьян гаиләсендә.
- 1935 нче елны авылда тулы булмаган урта мәктәпне тәмамлый.
-1937-1941 нче елларда Башкорт педагогия институтының тел-әдәбият бүлегендә укый.
- Бай табигатьле Келәш авылында, эш сөючән авылдашлары арасында. Ул чал тарих буе килә торган халык йолалары, гадәт-шөгылен ул үзе күреп үсә, әсәрләрендә дә аларга зур урын бирә.
- Сугышта катнаша, яралана.
- “Европа - Азия” шигырь җыентыгы. “Өченче көн тоташ кар ява” шигыре, “Озын – озак балачак” повесте.

«Бу китап,могҗизаларга ышанучан, сәеррәк, шаукымлырак, беркатлырак, чаярак кешеләр турында”.

М.Кәрим.








News.city.zt.ua






durdom-dom2.ru

- **Офык** – ***горизонт, күк йөзе белән җир арасындагы күз күреме күрә алган җир***
- **Гамәл** – ***эш-хәрәкәт***
- **Иминлек** – ***тынычлык, исәнлек***
- **Хакыйкать** – ***дөреслек***
- **Иман** – ***инану, ышану***
- **Инәй** - ***әни***

- Сер – *беленмәгән, ачылмаган вакыйга*
- Нур – *нинди дә булса яктылык чыганагыннан сузылган яктылык*
- Тәүфыйк - *әдәп, тәрбия*
- Дәрман - *көч (Дәрт бар,дәрман юк)*
- Кодрәт – *көч, ихтыяр*
- Рәхим – *мәрхамәт, шәфкать*
- Ялвару – *бик нык үтенеп сорау*

-Әнинең бәбигә чирләве

- ярдәмгә Олы инәйне чакыру

-сабый туганны көтү

- сабый туу

-бәбине хөрмәтләү йолалары

-кечкенә геройның балалар гел туып торсын өчен теләк, чаралары.

# Дөньяга яңа кеше туу, сабый туу вакыйгасы.



“Кендек әбисе”.

Олы Инәй бу авылда яшәүче һәр анага бала тудыруда ярдәм итә. Кармы, яңгырмы, җилме, давылмы, җәйме, кышмы дөньяга сабый туа, Олы Инәй һәрчак әзер, бернигә карамыйча ярдәмгә ашыга.

Бала тугач та китеп бармый,
аңа тәмам аякка басканчы булыша.

# “Кендек бабасы”.

Кечкенә геройны  Олы Инәй һәрвакыт үзе белән ияртеп  йөри.

Читтән генә булса да “Кендек” бәби туу процесында катнаша.

Бала туу кимесә, аллага ялварып бала тууын сорый, тылсым көче белән дә тумасলармы дип уйлый.

Ул бик кызыксынучан, сабыр, юмарт.

Иптәшләре аңа “Кендек” кушаматы кушканнар.

Кара Йомагыл бик эшчән. Хатыны бәбигә чирләгәч тә ул вакытын бушка, әрәмгә уздырмый, үзе түземсезлек белән малай тууын көтә, хатыны өчен борчыла, шул арада юкәдән аркан ишә. Эш белән мәшгуль.

Юмарт кулга мал керер.
Ирем кисәге – итем кисәге.
Теле телгә йокмый.
Ай үсәсен көн үсә.
Арык атның күгәне киң.
Бер кыенның мең рәхәте.
Бер кышка куян тиресе
дә чыдаган

# Тест.

**1.“Озын-озак балачак” повестенең авторы кем?**

а) Фатих Кәрим

б) Әмирхан Еники

в) Мостай Кәрим

**2. “... Һәркайсыбызның үз хакыйкате, үз иманы Вазифа. Без икебез бер дөреслек белән яши алмыйбыз. Хаклы булсам да, мин үзем өчен генә хаклымын...” Кем сүзләре?**

а) Кече Инәй

б) Кара Йомагыл

в) Олы Инәй

**3. Өзектәге тылсымлы дип исемләнгән агач?**

а) алмагач

б) чикләвек

в) каен

**4. Кендек Кара Йомагылларга барганда, нәрсә суырып бара?**

а) өрек

б) конфет

в) борчак

**5. Кара Йомагыл улына нинди исем кушмакчы була?**

а) Ибраһим

б) Хәбибулла

в) Гайнетдин

# Өй эше.

1. “Искәндәр Әсгате” бүлеген укырга.
2. Өзектәге аңлашылмаган сүзләргә аңлатмалы сүзлектән жаваплар язып килергә